СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон (8552) 70-00-33, факс 70-12-61, tukay.rt@tatar.ru

30.07.2024 № 12/3

На №__________от______________

**КАРАР**

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коррупцион хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турында» нигезләмә хакында» Тукай муниципаль районы Советының 2013 елның 19 апрелендәге 21/5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 13 июнендәге 258-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль район Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коррупцион хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турында» нигезләмә хакында» Тукай муниципаль районы Советының 2013 елның 19 апрелендәге 21/5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. I бүлекнең 1.15 пункты 6 абзацында «дөрес булмаган яки» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

1.2. II бүлекнең 2.4 пункты 2 абзацында «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, эшкә алучы вәкиле булган муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора» сүзләрен өстәргә.

1.3. II бүлекнең 2.4 пункты 3 абзацына түбәндәге эчтәлектәге өлешне өстәргә: «муниципаль хезмәткәргә әлеге пунктта күрсәтелгән белә торып дөрес булмаган белешмәләрне тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.».

1.4. II бүлекнең 2.5 пункты 2 пунктчасында «яки «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан бирелгән» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru), Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы урынбасары,
Совет рәисе урынбасары

Р.И. Закиров